**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары**

03.10.2016ел. № 27

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитетының «җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 3 октябрендәге 26 номерлы карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге Советы Карарын кабул итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:
"2017 елда Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр баладан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне оештыру:
- Келәнче, Бикә авыллары эчендәге чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чор).
- торак пунктлардагы каты көнкүреш калдыклары вакытлы полигоннарын карап тоту һәм чистарту:
Келәнче авылы, Бикәй авылы.
- чишмәләрне ремонтлау: Келәнче авылы.

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
- янгын гидрантларын урнаштыру : Келәнче авылы
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Г. Тукай урамы, Татарстан урамы буенча вак таш җәелгән юлны ремонтлау .
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- Келәнче авылы Келәнче бистәсендә су белән тәэмин итү системасын ремонтлау
2. Бу карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерү:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Келәнче авылы, Г. Тукай ур., 35,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Бикәй авылы, Фрунзе ур.;
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Советы Рәисе Д. А. Кадыйров